КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 22 сентябрь г.Казань № 900

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру өчен кирәкле документлар формаларын раслау хакында» 2008 ел, 31 гыйнвар, 57 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 8 октябрь, 914 нче; 2020 ел, 24 февраль, 131 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Исәпкә алу эшен алып бару тәртибендә:

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) гариза бирүче гражданның гаилә составын раслый торган документларның («Гражданлык хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык йә гаилә әгъзасы итеп тану турында, уллыкка (кызлыкка) алу турында суд карары (билгеләмәсе)) күчермәләре;»;

уналтынчы абзацта «һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматларны бирү» сүзләрен төшереп калдырырга;

уналтынчы абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«з[1]) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокуклары теркәлмәгән күчемсез мөлкәт объектларына хокукны билгели торган документлар;»;

унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«мөлкәт хокукларын теркәүгә алуны гамәлгә ашыручы органнардан гражданнарның салым салынырга тиешле милек хокукындагы күчемсез һәм күчемле

мөлкәткә ия булуның хокукый нигезләрен раслый торган документларның күчермәләре;»;

әлеге карар белән расланган социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынга мохтаҗ буларак исәпкә алу өчен гариза формасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган тапшырылган документларны алу турында расписка формасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2018 ел, 7 июнь, 432 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 4 апрель, 271 нче; 2020 ел, 24 февраль, 131 нче; 2020 ел, 29 сентябрь, 884 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктта:

2 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 (6 өлешеннән тыш), 13 һәм 15 статьяларында күрсәтелгән документлар;»;

түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокуклары теркәлмәгән күчемсез мөлкәт объектларына хокукны билгели торган документлар.»;

2.4 пунктта:

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) дәүләт кадастр исәбенә алуны, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып баруны гамәлгә ашыручы органнан гариза бирү елы алдыннан килгән 5 ел өчен гариза бирүченең хокукка сәләтле һәр гаилә әгъзасы тарафыннан гаилә әгъзаларының даими яшәү урыны буенча милек хокукында торак урыннары булу яки булмау турында бирелә торган мәгълүматлар;»;

түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пунктча өстәргә:

«$3^{1)}$ гариза бирүче гражданның гаилә составын раслый торган документларның («Гражданлык хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык йә гаилә әгъзасы итеп тану турында, уллыкка (кызлыкка) алу турында суд карары (билгеләмәсе)) күчермәләре;»;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2008 ел, 31 гыйнвар, 57 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 22 сентябрь, 900 нче
карары редакциясендә)

Форма

Расписка

______________________________________________________________________ тарафыннан
(вәкаләтле орган исеме)

гражданның ____________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

аны социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынга мохтаҗ буларак исәпкә алу өчен документларын алу турында бирелде.

Алынган документлар исемлеге *:

1.____________________________________________________________________________
2.____________________________________________________________________________
3.____________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
(вәкаләтле органның документларны кабул итеп алган вазыйфаи заты имзасы,
Ф.И.Ат.ис.(соңгысы – булганда))

Документларны алу датасы һәм вакыты 20 ____ ел, «___» ___________, ____ сәг. ___ мин.

Документларны граждан ____________________________________________________ бирде
(Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)) (имзасы)

20___ ел, «___» __________

---

*Документлар исемлеген тутырганда, аларны кабул итеп алучы зат распискада алынган документларның битләр һәм нөсхәләр санын, шулай ук аларның төрен (төп нөсхәсе яки билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәсе икәнен) күрсәтергә тиеш.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 31 гыйнвар, 57 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 22 сентябрь, 900 нче карары редакциясендә)

Форма

Вәкаләтле орган җитәкчесе
______________________________________________________________
(җирлек, шәһәр округы) граждан
______________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))
______________________________________________________________
(адресы буенча яшәүче:
______________________________________________________________
почта индексы, тулы адресы, элемтәгә керү өчен телефоны)
______________________________________________________________
(көне, ае, елы)
______________________________________________________________
(түбәндәге адресы буенча теркәлгән: почта индексы, тулы адресы )
______________________________________________________________
(көне, ае, елы)

Гариза

___________________________________________________________________________ бәйле рәвештә
(гражданны социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынга мохтаҗ дип тану нигезләрен күрсәтергә, шулай ук гариза федераль закон, Россия Федерациясе Президенты указы яки Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән категориягә кертелгән граждан тарафыннан бирелгән очракта, тиешле категорияне күрсәтергә)

___________________________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________________________

мине (__________ кешедән торган гаилә составында) социаль наем шартанмәсе буенча бирелә торган торак урынга мохтаҗ буларак исәпкә куюны, шулай ук (кирәк булган очракта) мине (минем гаилә әгъзаларын) аз керемлеләр дип тануны сорыйм.

Үзем турында: мин ____________________________________________________________ эшләвемне хәбәр итәм
(оешма, цех, бүлек исемен күрсәтергә)

___________________________________________________________________________________________

_______________ ______ елдан _____________________________________________ вазыйфасында
(көне, ае)

Минем гаилә _____ кешедән тора (туганлык, яше буенча, кайсы вакыттан алып яшәвен

күрсәтергә):
___
___
___

Мин һәм минем балигъ булган гаилә әгъзалары салым, таможня һәм башка органнарга үзебез тапшырган керемнәр һәм мөлкәт турындагы мәгълүматларны вәкаләтле орган тарафыннан тикшерүгә ризалык бирәбез.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары, безне исәпкә алган очракта, гаризада күрсәтелгән мәгълүматлар үзгәргәндә без бер ай эчендә бу турыда исәпкә алу урыны буенча вәкаләтле органга язма рәвештә хәбәр итәргә, шулай ук безне торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптә торучы гражданнар буларак яңадан теркәү өчен, керемнәрнең күләмен һәм безнең мөлкәтнең кыйммәтен яңадан бәяләү өчен тиешле документларны билгеләнгән срокларда һәм тәртиптә тапшырырга тиеш турында кисәтелде.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары үзебез тапшырган документларда чынбарлыкка туры килми торган һәм исәпкә алу өчен нигез булып торган мәгълүматлар ачыкланган очракта, законнар белән билгеләнгән тәртиптә исәптән төшереләчәгебез белән килешәбез.

Кушымта*:

1. Социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынына мохтаҗ буларак гражданны (гаилә әгъзаларын) исәпкә алу өчен кирәкле документлар:
1. ___
2. ___
3. ___
___

2. Гражданны (гаилә әгъзаларын) аз керемле дип тану өчен кирәкле документлар:
1. ___
2. ___
3. ___
___

3. Гражданның федераль закон, Россия Федерациясе Президенты указы яки Татарстан Республикасы законы нигезендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алынырга хокукын раслый торган документлар:
1. ___
2. ___
3. ___
___

Гариза бирүче ___ ___
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)) (имзасы)

Гаиләнең хокукка сәләтле әгъзалары:
1. ___ ___
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)) (имзасы)
2. ___ ___
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)) (имзасы)
3. ___ ___
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)) (имзасы)
___ ___
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)) (имзасы)

* Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен кирәкле документлар исемлеге һәм аларны тапшыру тәртибе Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән.

20____ ел, «______________» ________________________

(датаны сүз белән)

Документларны кабул итте _________________________________________________ __________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)) (имзасы)

20___ ел, «___» __________

_________________________________